ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

29 март, 2023 ел № 22/8

Шәһәр Советының 2018 елның 8 ноябрендәге 27/16 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә шәһәр төзелеше мәсьәләләре буенча иҗтимагый фикер алышу яисә җәмәгать тыңлауларын оештыру һәм үткәрү Тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында һәм «Россия Федерациясендә тимер юл транспорты турында» Федераль законның 16 статьясы 2 пунктындагы икенче абзацының үз көчен югалтуын тану хакында» 2022 елның 29 декабрендәге 612-ФЗ номерлы Федераль законның 1 статьясы, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының 2018 елның 8 ноябрендәге 27/16 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә шәһәр төзелеше мәсьәләләре буенча иҗтимагый фикер алышу яисә җәмәгать тыңлауларын оештыру һәм үткәрү Тәртибенә (Шәһәр Советының 2019 елның 7 октябрендәге 33/10, 2020 елның 28 маендагы 39/10, 2021 елның 4 августындагы 8/9, 2022 елның 22 августындагы 16/10, 2022 елның 8 декабрендәге 18/12 номерлы Карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 1 пунктчада «кимендә бер ай һәм өч айдан да артык булмаган» сүзләрен «бер айдан артмый» сүзләренә үзгәртергә;

2) 2 пунктчада «кимендә бер ай һәм өч айдан да артык булмаган» сүзләрен «бер айдан артмаган» сүзләренә үзгәртергә;

3) 3 пунктчада «бер ай һәм өч айдан артык» сүзләрен «ундүрт көн һәм утыз көннән артык» сүзләренә үзгәртергә.

2. Әлеге Карар үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының шәһәр төзелеше, шәһәр инфраструктурасын һәм торак-коммуналь хуҗалыкны үстерү мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә, Башкарма комитет Җитәкчесе Ф.Ш.Салаховка йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев